КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 1 сентябрь г.Казань № 744

2019 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәрен;

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга норматив чыгымнарын;

эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга нормативларны, дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативларын раслау турында» 2017 ел, 5 сентябрь, 639 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 1 сентябрь, 744 нче
карары белән расланды

2019 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре

(кеше)

| Т/с | Оешмалар | Дәваланып бетү (тернәкләнү) өчен җибәрелә торган барлык авырулар | Шул исәптән стационарда дәваланганнан соң | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | көчле миокард инфарктын, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына, тотрыксыз стенокардиягә операцияләрне | баш мие кан әйләнеше нык бозылуны | умыртка сөяге үсешендәге җитешсезлекләр һәм кимчелекләр, буыннар пластикасы, эндопротезлар һәм реэндопротезлар ясаганда, кул-аякларны реплантацияләгәндә ортопедия, травматология операцияләрен | риск төркемнәрендәге йөкле хатыннар авыруларын | шикәр диабетын |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Шифаханә-курорт оешмалары | 4921 | 2187 | 368 | 122 | 1923 | 321 |
| 2. | Дәүләт медицина оешмалары, | 657 | - | 603 | 54 | - | - |
| | шул исәптән: | | | | | | |
| 2.1. | Яр Чаллы шәһәренең «Сугышлар ветераннары госпитале» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 359 | | 305 | 54 | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.2. | «Республика клиник невролоогия үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе | 298 | | 298 | | | |
| | Барлыгы | 5578 | 2187 | 971 | 176 | 1923 | 321 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 1 сентябрь, 744 нче
карары белән расланды

2019 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң
турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында
дәвалап бетерүне (тернәкләндерүне) оештыруга
норматив чыгымнары

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) юнәлеше исеме | Норматив чыгымнар, койка-көн өчен сум |
|---|---|---|
| 1. | Көчле миокард инфарктын, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына, тотрыксыз стенокардиягә операцияләрне стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1279,72 |
| 2. | Баш мие кан әйләнеше нык бозылуны стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1273,55 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендәге җитешсезлекләр һәм кимчелекләр, буыннар пластикасы, эндопротезлар һәм реэндопротезлар ясаганда, кул-аякларны реплантацияләгәндә ортопедия, травматология операцияләреннән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1257,12 |
| 4. | Риск төркемнәрендәге йөкле хатыннар авыруларын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1254,98 |
| 5. | Шикәр диабетын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 1250,89 |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 1 сентябрь, 744 нче
карары белән расланды

2019 елга эшләүче гражданнарны стационарда дәваланганнан соң турыдан-туры шифаханә-курорт оешмасы (дәүләт медицина оешмасы) шартларында дәвалап бетерү (тернәкләндерү) вакыты дәвамлылыгы нормативлары

| Т/с | Дәвалап бетерү (тернәкләндерү) юнәлеше исеме | Дәвалап бетерүнең (тернәкләндерүнең) дәвамлылыгы, календарь көннәр |
|---|---|---|
| 1. | Көчле миокард инфарктын, йөрәккә һәм магистраль кан тамырларына, тотрыксыз стенокардиягә операцияләрне стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 2. | Баш мие кан әйләнеше нык бозылуны стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 3. | Умыртка сөяге үсешендәге җитешсезлекләр һәм кимчелекләр, буыннар пластикасы, эндопротезлар һәм реэндопротезлар ясаганда, кул-аякларны реплантацияләгәндә ортопедия, травматология операцияләреннән соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 4. | Риск төркемнәрендәге йөкле хатыннар авыруларын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |
| 5. | Шикәр диабетын стационарда дәвалаганнан соң турыдан-туры дәвалап бетерү (тернәкләндерү) | 21 |